**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 13** **27.11.2022 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Бәйрәкә авыл
җирлегене составына керүче Бәйрәкә
авылында узган гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2022 елның 22 һәм 27 ноябрь көннәрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «2023 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Россия армиясе сафларында хезмәт итүчеләрнең тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1200 сум күләмендә, ә 2 группа инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?":

- юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылы Вахитов урамындагы юл - урам челтәрен норматив халгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш, асфальт сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылы Сельхозтехника урамындагы зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү) - карарын кабул ителде дип санарга.

**ӘЙЕ** **ЮК**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 890 граждан кергән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 448 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 259 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 189 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегенә керүче Бәйрәкә авылында гражданнар җыены узган һәм аның нәтиҗәләре гамәлдә дип санарга.

2. «2023 елда Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Россия армиясе сафларында хезмәт итүчеләрнең тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1200 сум күләмендә, ә 2 группа инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?":

- юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылы Вахитов урамындагы юл - урам челтәрен норматив халгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш, асфальт сатып алу, нигез салу, ташу, җәю, эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылы Сельхозтехника урамындагы зират территориясен ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Бәйрәкә авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Бәйрәкә авылындагы урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү) - карарын кабул ителде дип санарга.

3.Җыен нәтиҗәләрен Бәйрәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan электрон адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга www.yutaza.tatar.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О. Әхмәтшина